Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иж-Бубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Иж-Бәйки торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**23.11.2023 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның "23" ноябрендә 09 сәгать 00 минутта уткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга: "2024 елда үзара салым акчаларын кертү өчен «Иж-Бубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иж-Бәйки авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, ирекле киткән) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатыннарын, балигъ булмаган балаларын) түләүдән азат итү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юллау белән килешәсезме:

1) Халыкның күпләп ял итү урыннарын ремонтлау һәм Иж-Бәйки торак пунктының тирә-ягын төзекләндерү:

- тракторны карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, трактор өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу;

2) Иж-Бәйки торак пунктында яшәүчеләргә су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су суырту башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су коймасын тәэмин итүче башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

3) Иж-Бәйки торак пунктын ремонтлау, киртәләр төзү, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү:

- койма өчен материаллар сатып алу;

4) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту:

- юллар өчен вак таш сатып алу һәм җәю.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 138 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 72 кеше кертелгән, бу 52 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 70 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 2 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иж-Бубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иж-Бәйки торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. I төркем инвалидларыннан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче затлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгән, ихтыярый затлар) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (ата-аналар, ир белән хатын, балигъ булган балалар), ирегеннән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, 2024 елда Иж-Бубый авыл җирлеге территориясенең Иж-Бәйки торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

3. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Халыкның күпләп ял итү урыннарын ремонтлау һәм Иж-Бәйки торак пунктының тирә-ягын төзекләндерү:

- тракторны карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, трактор өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу;

2) Иж-Бәйки торак пунктында яшәүчеләргә су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су суырту башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су коймасын тәэмин итүче башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

3) Иж-Бәйки торак пунктын ремонтлау, киртәләр төзү, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү:

- койма өчен материаллар сатып алу;

4) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту:

- юллар өчен вак таш сатып алу һәм җәю.

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Совет Иж-Бобьинского сельского поселения
Иж-Бубый авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002480

Халык җыенында рәислек итүче,
Авыл җирлеге башлыгы Р.Р. ВАҺАПОВ